ГЛАВА
Бимского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Бима авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

23.11.2021 Бима № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башлыгы к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2021 елның 04 декабрендә 12 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2021 елның 04 декабрендә 13 сәг 00 мин билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: Бима авылының Ленин, К.Маркс, Хезмәт, М.Горький урамында яшәүчеләр.

-2 этап: Бима авылының Нагорная, Совет, Пролетарская, Мәктәп, Яшьләр урамында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында

торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Бима торак пунктында К.Маркс урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм җәю);

2. Бима торак пунктында урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтү, ремонтлау, лампаларны һәм фонарьларны алыштыру. Килешү буенча түләү;

3. Бима торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү (ремонтлау, хезмәт күрсәтү, тирән насослар, колонкалар һәм башка материаллар сатып алу);

4. Бима торак пунктындагы урамнарны кардан чистарту (дизель ягулык һәм майлар сатып алу) .

5. Янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм ремонтлау. Янгын сүндерү машинасы шоферына килешү буенча түләү

6. Бима торак пунктында бензин триммеры (моточапкыч) һәм төзекләндерү өчен җиһазлар сатып алу. Килешү буенча түләү.

7.МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү. Тракторчыга килешү буенча хезмәт хакы түләү.

8.Гаражны агымдагы ремонтлау өчен материалларны сатып алу, ремонт башкару.

9. Бима торак пунктында үлән һәм чүп үләннәрен чабу. (дизель ягулык һәм майлар сатып алу).

10.Мәйдан бизәү өчен материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы Бима ав., Ленин урамы, 1 йорты, мәдәният йорты янында уздырырга.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Э.И.Михайлов